ГЛАВА КАРАКАШЛИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЮТАЗИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Сирина Батыршина, д.33,
с.Каракашлы, 423961

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ КӘРӘКӘШЛЕ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Сирин Батыршин урамы, 33 йорт,
Кәрәкәшле авылы, 423961

Тел.:(85593) 4-21-34, факс:4-21-21, e-mail: Karak.Utz@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**№ 5** **8 ноябрь 2023 ел**

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Кәрәкәшле авыл җирлегенең Кәрәкәшле торак пунктында 2024 елда Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Кәрәкәшле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә гражданнарга үзара салым (бер тапкыр түләнә торган түләүләр) акчаларын кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 20, 35 маддәләре, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлеге Советының 2019 елның 17 июлендәге 10 санлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 14, 81 маддәләре, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Кәрәкәшле авыл җирлеге Советының 2019 елның 28 октябрендәге 20 санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Кәрәкәшле авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында»гы нигезләмә нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. 2023 елның 21 ноябренә 14 сәгать 00 минутка Татарстан Республикасы, Ютазы районы, Кәрәкәшле авылы, Мирфатих Зәкиев урамы, 19 йорт адресы буенча урнашкан мәдәният йорты бинасы янында Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлегенең Кәрәкәшле авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

«Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Кәрәкәшле авыл җирлегенә керүче Кәрәкәшле торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән, Украинада махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның якын туганнарыннан (әти-әниләре, тормыш иптәшләре, балигъ булган балалары), Украинада махсус хәрби операциядә һәлак булганнарның якын туганнарыннан (әти-әниләре, тормыш иптәшләре, балигъ булган балалары), 1 группа инвалидлардан тыш, 2024 елда 400 (дүрт йөз) сум күләмендә үзара салым (бер

тапкыр бирелә торган түләүләр) кертүгә сез ризамы һәм әлеге акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә ризамы:

- Кәрәкәшле торак пунктында зират территориясен киртәләү (төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча эшләрне түләү);

- Кәрәкәшле торак пунктындагы Мирфатих Зәкиев урамында тротуар төзү, (смета буенча: таш, асфальт сатып алу, нигезне әзерләү, ташу, җәю, эшләрне түләү);

«РИЗА» «КАРШЫ».

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Каракашлы авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасының Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталы составында "Рәсми Татарстан" дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының бердәм порталы составында "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми рәвештә игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Ютазы муниципаль районы
Кәрәкәшле авыл җирлеге башлыгы А.Г.Дәүләтгәрәев